| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 06.03.2015 г. Казань № 10-5/кс

***Рамазанов Рифхат Харрасович» ИПе өчен 2015 елга эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «2015 елга су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларны үзгәртүнең мөмкин булган максималь чик индексларын уртача Россия Федерациясе субъектлары буенча билгеләү турында» 2014 елның 11 октябрендәге 228-э/4 санлы тарифлар буенча Федераль хезмәт боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Рамазанов Рифхат Харрасович» ИПе өчен эчәргә яраклы суга тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасындагыча билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 апреленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. «Рамазанов Рифхат Харрасович» ИПенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча Дәүләт
комитеты карарына кушымта
06.03.2015 № 10-5/кс

## «Рамазанов Рифхат Харрасович» ИПе өчен 2015 елга, календарь чорларына бүлеп, эчәргә яраклы суга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су бүлүне башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 апреленнән 2015 елның 30 июненә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | | |
| 1 | «Рамазанов Рифхат Харрасович» ИПе * | 19,69 | 21,14 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге